СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 14 » июль 2026 ел №19

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган территория чикләрен билгеләү турында**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында” 2014 елның 02 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Яңасала авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган, үз эченә Яңасала, Каенсар авылы торак пунктларын алган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге чикләрен территория чикләре дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советының “Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында” 2014 елның 17 декабрендәге 69 номерлы карарларын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңасала авыл
җирлеге башлыгы




А.И.Сафин